ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 901 «16» 12 2019 ел

Татарстан Республикасы Спас муниципаль
районы Башкарма комитетының «2019-2021
елларга халыкның сәламәтлеген яхшырту
һәм үлем санын киметү» программасын раслау
турында «гы 11.01.2019 ел, № 6 карары белән
расланган «2019 – 2021 елларга халыкның
сәламәтлеген яхшырту һәм үлем санын киметү»
муниципаль программасына үзгәрешләр кертү
турында (21.03.2009, № 190, 21.11.2019 ел, № 831)

Халыкның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Спас муниципаль районының «2019-2021 елларга халыкның сәламәтлеген яхшырту һәм үлем санын киметү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Спас муниципаль районының «Халыкның сәламәтлеген яхшырту һәм 2019-2021 елга үлем очракларын киметү» район максатчан программасын үтәү чараларын» 18 нче бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 18 | Бөер эшчәнлеге җитешсезлеге булган авыруларны дәвалау урынына бару чыгымнарын компенсацияләү (гемодиализ) | | 2019 ел<br>2020 ел<br>2021 ел | Район бюджеты<br>432,0<br>533,0<br>533,0 |

1.2. Спас муниципаль районының «Халыкның сәламәтлеген яхшырту һәм 2019-2021 елга үлем очракларын киметү» район максатчан программасын үтәү буенча чаралар бүлегенә түбәндәгеләрне өстәргә:

- түбәндәге эчтәлекле юллар:

| Янгыннарда үлемнәрне киметү гамәлләре | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 55 | Автомат янгын хәбәрчеләре сатып алу | Авыл җирлекләре башлыклары, Болгар шәһәр башкарма комитеты | 2019 ел<br>2020 ел<br>2021 ел | Район бюджеты<br>25,2<br>30,0<br>30,0 |

2. «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге финанс-бюджет палатасына чараларны финанслауга акчалар кертергә.
3. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http:// www. spassriy.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (htth:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җитәкченең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.В. Савиновка йөкләргә.

ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе В. А. Осокин